ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАДУВАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

« 24» июль 2019 — №20

Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен
махсус урыннар (махсус урын) бирү һәм җиһазлау турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен, һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм урнаштыру турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында» гы 10 июль 2019 ел 67/516 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Һәрбер сайлау участогы территориясендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар (махсус урын) бирергә һәм җиһазларга 1 кушымта нигезендә.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башкарма комитетына кушымта нигезендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар (махсус урын) булдырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемә алам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев

Карадуган авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына кушымта
“2019 елның 24 июле” № 20

Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен
махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар алресы | Элү урыны исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), бина диварында, фойеда һәм тд.) |
|---|---|---|
| 1064 | Карадуган авылы, Себер тракты урамы, 51 йорт | МБГБУ “Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе” каршындагы мәгълүмат стенды |
| 1065 | Түбән Кенә авылы, Ю.Гагарин урамы, 26/1 йорт | «Почта России»бинасы каршындагы мәгълүмат стенды |